ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында” Татарстан Республикасы Законына һәм Татарстан Республикасының аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2015 елның 25 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру турында” 2004 елның 26 июлендәге 43-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 7 (I өлеш); 2007, № 8; 2009, № 6, № 9 – 10; 2011, № 4 (I өлеш), № 10 (I өлеш); 2012, № 3; 2014, № 1 – 2; 2015, № 4) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2 статьяда:

а) 1 пунктта “ачык” сүзен төшереп калдырырга;

б) 2 пунктның икенче абзацында “ачык” сүзен төшереп калдырырга;

в) $6^1$ пунктта “рәсми матбугат басмасы һәм” сүзләрен төшереп калдырырга, “сайт” сүзеннән соң “(алга таба – “Интернет” челтәрендәге рәсми сайт)” сүзләрен өстәргә;

г) 7 пунктта “массакүләм мәгълүмат чараларында һичшиксез басылып чыгарга” сүзләрен “Интернет” челтәрендәге рәсми сайтларда һичшиксез урнаштырылырга” сүзләренә алмаштырырга;

2) 3 статьяның 3 өлешендәге 7 һәм 9 пунктларында “ачык” сүзен төшереп калдырырга;

3) 4 статьяның 2 һәм $2^1$ өлешләрендә “ачык” сүзен төшереп калдырырга;

4) түбәндәге эчтәлекле $6^1$ статья өстәргә:

“$6^1$ статья. **Бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын тапшыру**

Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планына (программасына) кертелгән унитар предприятиеләр, акционер җәмгыятьләр һәм җаваплылыгы чикләнгән җәмгыятьләр башкарма хакимиятнең вәкаләтле органына еллык бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын, Россия Федерациясенең бухгалтерлык хисабы турындагы законнарында аның мәҗбүри нөсхәсен, кварталлык, ярты еллык, тугыз айлык арадаш бухгалтерлык (финанс) хисаплылыгын тапшыру өчен билгеләнгән срокта, әлеге хисаплылыктагы мәгълүматны “Интернет” челтәрендәге Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән рәсми сайтта урнаштырып, хисап чоры тәмамланган көннән алып утыз көннән дә соңга калмыйча тапшыра.”;

5) 8 статьяның 2 өлешендә:

а) унберенче һәм уникенче абзацларда “ачык” сүзен төшереп калдырырга;

б) унбишенче абзацта “ачык” сүзен төшереп калдырырга;

6) 9 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“1. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыруның фаразлау планы (программасы), дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турындагы карарлар, күрсәтелгән мөлкәтне сату турында һәм аны сату нәтиҗәләре хакында мәгълүмати хәбәрләр, дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру нәтиҗәләре турында еллык мәгълүмат “Интернет” челтәрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән рәсми сайтта, шулай ук торглар үткәрелү турында мәгълүмат урнаштыру өчен “Интернет” челтәрендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән Россия Федерациясе рәсми сайтында (алга таба – “Интернет” челтәрендәге сайтлар) урнаштырылырга тиеш.”;

б) түбәндәге эчтәлекле $1^1$ өлеш өстәргә:

“$1^1$. Дәүләт мөлкәтен сату турында, аны сату нәтиҗәләре хакында мәгълүмати хәбәр шулай ук дәүләт мөлкәтен сатучының “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырыла.”;

в) 2 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2. “Интернет” челтәрендәге сайтларда урнаштырыла торган дәүләт мөлкәтен сату турында мәгълүмати хәбәрдә, шулай ук дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру алыш-бирешләренең нәтиҗәләре турында мәгълүматта хосусыйлаштыру турындагы федераль законнарда билгеләнгән белешмәләр күрсәтелергә тиеш.”;

г) 3 өлештә “рәсми матбугат басмасында бастырып чыгарылырга, шулай ук” сүзләрен төшереп калдырырга;

д) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

“3[1]. Дәүләт мөлкәтен хосусыйлаштыру шартлары турында карар, кабул ителгән көненнән алып ун көн эчендә, “Интернет” челтәрендәге сайтларда урнаштырылырга тиеш.”;

е) 4 өлештә “рәсми матбугат басмасында бастырып чыгарылырга,” сүзләрен төшереп калдырырга, “утыз” сүзен “ун” сүзенә алмаштырырга;

7) 10 статьяның исемендә һәм 1 өлешендә “ачык” сүзен төшереп калдырырга;

8) 11 статьяның беренче һәм җиденче абзацларында “ачык” сүзен төшереп калдырырга;

9) 13 статьяның 2 өлешендә “Дәүләт һәм муниципаль мөлкәтне хосусыйлаштыру турында” Федераль законның 32 статьясындагы 5 пунктында билгеләнгән срок чыккан мизгелдән” сүзләрен “бәясен игълан итмичә дәүләт мөлкәтен сатуга йомгак ясаган көннән алып” сүзләренә алмаштырырга;

10) 16 статьяда:

а) 3 өлештә “басылып чыгарга тиеш” сүзләрен “булырга тиеш” сүзләренә алмаштырырга;

б) 4 өлештә “бастырып чыгарылган” сүзләрен “Интернет” челтәрендәге сайтларда урнаштырылган” сүзләренә алмаштырырга;

11) 19 статьяда:

а) исемдә, 1 – 3 өлешләрдә “ачык” сүзен төшереп калдырырга;

б) 4 өлештә “ачык” сүзен төшереп калдырырга.

**2 статья**

“Хуҗалык җәмгыятьләренең һәм ширкәтләренең идарә һәм контроль органнарында дәүләт вәкилләренең катнашу тәртибе турында” 2000 елның 19 октябрендәге 383 номерлы Татарстан Республикасы Законының преамбуласында, 1 статьясында, 2 статьясындагы беренче өлешендә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 11 (9); 2005, № 12 (I өлеш) “ачык” сүзен төшереп калдырырга.

**3 статья**

“Татарстан Республикасы дәүләт мөлкәте белән идарә итү һәм эш итү турында” 2007 елның 26 июлендәге 35-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 3 статьясындагы 3 өлешенең 2 пунктында (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 7 (II өлеш); 2011, № 10 (I өлеш) “ачык” сүзен төшереп калдырырга.

**4 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2015 елның 7 октябре
№ 70-ТРЗ